КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 11 декабрь г.Казань № 971

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» 2011 ел, 23 май, 416 нчы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» 2011 ел, 23 май, 416 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 11 февраль, 86 нчы; 2016 ел, 9 август, 543 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 23 май, 416 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 11 декабрь, 971 нче
карары редакциясендә)

Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 23 май, 416 нчы карары белән расланган төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

мәдәни мирас объектларын ремонтлау, консервацияләү һәм реставрацияләү;

мәдәни мирас объектларының бөтенлеген бозмый һәм аларның бозылу, җимерелү яки юкка чыгу куркынычын тудырмый торган хуҗалык эшчәнлеге;

саклау предметын тәшкил итүче үзенчәлекләрен үзгәртмичә функциональ файдаланырга рөхсәт ителгән төрләре нигезендә мәдәни мирас объектларын заманча файдалану өчен яраклаштыру;

мемориал һәм архитектура ансамбле буларак әһәмияткә ия булган югалган тарихи элементларын фәнни нигездә элекке хәленә кайтару - регенерацияләү;

мәдәни мирас объектының бөтенлеген боза торган вакытлыча корылмаларны һәм объектларны бетерү;

ядкәр территориясендә урнашкан, тарихи-шәһәр төзелеше, пространство-архитектура ягыннан һәм мемориал буларак зур әһәмияткә ия булмаган биналарның кыйммәтле элементларын консервацияләп һәм фасадларын реставрацияләп, мөмкин булганча техник модернизацияләп реконструкцияләү;

булган объектларның инженерлык инфраструктурасын (су белән тәэмин итү, канализация, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефон кертү буенча тышкы челтәрләрне) капиталь ремонтлау;

төзекләндерү – мәйданчыкларны, якын килү һәм транспорт узу урыннарын каплауда традицион материаллардан (таштан, граниттан һәм табигый булып күренә торган башка материаллардан) файдалану; тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирүче аерым тора торган яктырту җайланмасыннан файдалану;

яшелләндерү – агачларның кыйммәтле төрләрен саклау;

мәдәни мирас объектының беренче катыннан югары булмаган биеклектә мәдәни мирас объектлары фасадларында мәгълүмати язулар һәм билгеләр, мемориаль такталар кую;

оешмаларның элмә такталарын, җитештерүче (үтәүче, сатучы) исеме, аның урнашу урыны (адресы) һәм эш режимы турында мәгълүматны кулланучылар

игътибарына җиткерү өчен билгеләнгән элмә такталары «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә бинаның, төзелешнең яки корылманың беренче катыннан югары куймау. Югарыда билгеләнгән мәгълүмат конструкцияләренең биеклеге чикләрендә теге яки бу конструкцияне урнаштыру регламентлана торган катларның тәрәзәләре арасындагы аралык, фриз биеклегенең 2/3 өлешеннән артмаска тиеш. Аркалы тәрәзәләр булганда катларның тәрәзәләре арасында урнашкан конструкцияләрнең биеклеге 1/2 гә кадәр киметелә. Мәгълүмат конструкцияләренең киңлеге чикләрендә теге яки бу конструкцияне урнаштыру регламентлана торган аралыкның 2/3 өлешеннән артмаска тиеш.

Мәдәни мирас объектларының бердәм дәүләт реестрына (Россия Федерациясе халыклары тарихы һәм мәдәнияте һәйкәлләре) кертелгән мәдәни мирас объектларында, шулай ук аларның территорияләрендә, истәлекле урыннар территорияләреннән тыш, тышкы реклама урнаштыру рөхсәт ителми.

Мәдәни мирас объектларында, аларның территорияләрендә тышкы реклама таратуга кагылышлы мәдәни мирас объектларында һәм аларның территорияләрендә театраль-тамаша, мәдәни-агарту һәм тамаша-күңел ачу чаралары үткәрү турында бары тик мәгълүматны яки әлеге чаралар турында бары тик мәгълүматны үз эченә алган, бер үк вакытта төгәл бер чараның иганәчесе буларак билгеле бер зат турында әйтеп китеп, әгәр мондый исткәртмәдә реклама мәйданының (киңлегенең) бары тик 10 проценты гына бирелсә, әгәр мәдәни мирас объектларында һәм аларның территорияләрендә мондый тышкы реклама урнаштыру мәдәни мирас объектының милекчесе яки бүтән законлы хуҗасының сак йөкләмәләре таләпләренә туры килсә, әлеге Режимның унөченче абзацы таләпләре кулланылмый.

Югарыда күрсәтелгән барлык эшләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы биргән язмача рөхсәт һәм йөкләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы әлеге эшләрне башкаруны тикшерүдә тоткан шартларда башкарыла.

Әлеге карар белән расланган төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен урнаштыру, шулай ук җир төзелеше эшләрен, җир, төзелеш, хуҗалык эшләрен һәм мәдәни мирас объектларын саклауга бәйле булмаган башка эшләрне проектлау, үткәрү;

мәдәни мирас объектлары фасадында һәм түбәсендә кондиционерлар, эре габаритлы антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын кую;

җир өсте ысулы белән инженерлык инфраструктурасы объектларын (су белән тәэмин итү, канализация, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефон кертү буенча тышкы челтәрләр) үткәрү;

ачык һәм ябык автомобиль кую урыннары урнаштыру;

киосклар, павильоннар, өслекләр; кече архитектура формалары кую, югалганнарын торгызудан тыш;

агачның кыйммәтле төрләрен кисү, санитария максатында кисүдән башка.